ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабря 2019 ел № 6322

**Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын бәяләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясы 3 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын бәяләү тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 5 декабрендәге
6322 номерлы карарына
кушымта

Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын бәяләү тәртибе турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясының 3 пункты нигезендә эшләнде һәм юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгы күрсәткечләрен билгели.

2. Банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылыгы күрсәткечләре банкның яки башка кредит оешмасының (алга таба - гарант) һәм поручительләрнең финанс тотрыклылыгы белән билгеләнә.

3. Әлеге нигезләмәнең максатларында банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылыгы дигәндә гарантның һәм поручительнең бюджет кредитын кире кайтару буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең (алга таба – алучы) йөкләмәләрен вакытында һәм тулы күләмдә башкару сәләте аңлашыла. Башка төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Граждан кодексындагы, Россия Федерациясе Бюджет кодексындагы кебек мәгънәдә кулланылалар.

4. Тәэмин итү күләме бирелә торган бюджет кредитының, аның буенча процентларның һәм әлеге килешүдә каралган башка түләүләрнең күләмен капларга тиеш.

5. Йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итүне рәсмиләштерү Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан (алга таба – шәһәр бюджеты) бюджет кредиты бирелгәнгә кадәр башкарыла.

6. Шәһәр бюджетыннан бирелә торган кредитны тәэмин итү өчен бирелүче банк гарантиясен һәм поручительлекне бәяләү Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.3 статьясының 3 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Глава 2. Банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләү

7. Гарант түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1) ликвидацияләү, реорганизацияләү, бөлгенлеккә төшү процессында түгел;

2) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлек туктатылмаган;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурычы, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре, шулай

ук элегрәк Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләре юк;

4) банк операцияләре башкаруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

5) «Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә физик затларның Россия Федерациясе банкларындагы кертемнәре мәҗбүри иминият системасында катнашу (соңгы хисап датасына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Банкының рәсми сайтында урнаштырылган рәсми мәгълүматлар);

6) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан «Россия Федерациясенең Үзәк банкы (Россия Банкы) турында» 2002 елның 10 июлендәге 86-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри нормативларны бозган өчен чаралар күрелмәү (Россия Федерациясе Үзәк банкының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында соңгы хисап датасына урнаштырылган рәсми мәгълүматлар).

8. Әлеге нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган гарант финанс идарәсенә түбәндәге документларны бирә:

1) гарантның алучы йөкләмәләре буенча гарант булырга ризалык турында хаты;

2) гарантның гарант тарафыннан расланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;

3) салым органында исәпкә кую турында таныклыкның, дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның яисә бердәм дәүләт юридик затлар реестрындагы язуның гарант тарафыннан расланган күчермәләре;

4) гарантның ликвидацияләү, реорганизацияләү, бөлгенлеккә төшү процессында булмавын раслаучы документлар;

5) гарантның бер генә кеше башкара торган башкарма органының, гарант исеменнән килешүләр эшләүгә вәкаләтле башка затның һәм гарантның баш бухгалтерының вәкаләтләрен раслаучы, гарант тарафыннан расланган документлар (сайлау турында карар, билгеләнү турында боерык, вазыйфага керешү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе), шулай ук әлеге затларның нотариаль расланган имза үрнәкләре һәм гарантның мөһер оттиски;

6) банк гарантиясен бирү буенча килешү төзүгә (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә) гарант идарәсенең вәкаләтле органының ризалыгын (хуплавын) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе;

7) Россия Федерациясе Үзәк банкының банк операцияләрен башкаруга генераль лицензиясенең нотариаль расланган күчермәсе;

8) соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар буенча гарантның бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

9) бухгалтерлык балансы һәм хисап финанс елы өчен һәм гарант раслаган соңгы хисап датасына керемнәр һәм зыян турында хисап;

10) әлеге нигезләмәнең 8 пунктының 1 пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән елдан алдагы ел өчен гарантның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында гарант раслаган аудитор бәяләмәсе күчермәсе;

11) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча гарантның үз акчаларын (капиталын) исәпләү һәм, рөхсәт ителгән зурлыклар диапазонын күрсәтеп, соңгы хисап датасына мәҗбүри нормативлар күрсәткечләре;

12) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча мәҗбүри нормативлар турында мәгълүмат;

13) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча гарант активларының сыйфаты турында мәгълүмат;

14) гарантның җитәкче тарафыннан имзаланган һәм гарант мөһере белән расланган чиста активлары хисабы;

15) гарантның соңгы ярты ел дәвамында мәҗбүри резерв таләпләрен үтәве турында, клиентларның исәп-хисап документларын вакытында түләмәү фактларының булмавы турында, Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан гарантка карата кулланылган мәҗбүри йогынты чаралары булмавы турында Россия Федерациясе Үзәк банкы белешмәсе;

16) вәкаләтле вазыйфаи затлар кандидатураларын Россия Федерациясе Үзәк банкы белән килештерүне раслый торган документлар.

Гарант әлеге пунктның 3, 4, 8 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, финанс идарәсе аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Гарантның финанс хәле түбәндәге күрсәткечләр белән билгеләнә:

1) соңгы финанс елында һәм агымдагы елның узган чорында зыян күрмәве;

2) гарантның I һәм II категория сыйфатлы активлары гомуми активлар күләменең кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш;

3) гарантның Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри нормативларга туры килүе;

4) гарантның бирелә торган бюджет кредитының өчкә тапкырланган суммасы күләменнән ким булмаска тиешле чиста активларының күләме.

10. Гарантның финанс идарәсенә кергән документлары кергән көнне теркәлә.

11. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 8 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, финанс идарәсе, документлар теркәлгән датадан башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны гарантка кире кайтара.

12. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 8 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килгән очракта, финанс идарәсе тарафыннан банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләү үткәрелә.

Финанс идарәсе тапшырылган документларны, документлар теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә, гарантның әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган таләпләргә туры килүе һәм әлеге нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне исәпкә алып, аның финанс хәлен билгеләү предметына карый.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча финанс идарәсе гарантның финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү сәләте турында бәяләмә әзерли, бу хакта гарантка бәяләмәне әзерләү датасыннан башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

## 3 бүлек. Поручительлекнең ышанычлылыгын бәяләү

13. Поручитель түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1) ликвидацияләү, реорганизацияләү, бөлгенлеккә төшү процессында түгел;

2) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлек туктатылмаган;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурычы, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре, шулай

ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан элегрәк бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләре юк.

14. Әлеге нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган поручитель финанс идарәсенә түбәндәге документларны бирә:

1) поручитель йөкләмәләре буенча поручитель булырга ризалык турында хаты;

2) поручитель тарафыннан расланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;

3) салым органында исәпкә кую турында таныклыкның, дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның яисә бердәм дәүләт юридик затлар реестрындагы язуның поручитель тарафыннан расланган күчермәләре;

4) поручительнең бер генә кеше башкара торган башкарма органы, поручитель исеменнән килешүләр эшләүгә вәкаләтле башка затның һәм поручительнең баш бухгалтерының вәкаләтләрен раслаучы, поручитель тарафыннан расланган документлар (сайлау турында карар, билгеләнү турында боерык, вазыйфага керешү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе), шулай ук әлеге затларның нотариаль расланган имза үрнәкләре һәм поручительнең мөһер оттиски;

5) банк гарантиясен бирү буенча килешү төзүгә (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә) поручитель идарәсенең вәкаләтле органының ризалыгын (хуплавын) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе;

6) поручительнең ликвидацияләү, реорганизацияләү, бөлгенлеккә төшү процессында булмавын раслаучы документлар;

7) поручительнең хуҗалык эшчәнлеге башкаруга нотариаль расланган лицензия күчермәсе (поручитель башкара торган эшнең лицензия нигезендә башкарылуы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән булса);

8) поручительнең кредит оешмаларында ачылган хисаплары турында салым органы тарафыннан расланган белешмә;

9) поручительнең исәп-хисапларында акчасы булу һәм аларның картотекасындагы сумма турында банклар тарафыннан бирелгән белешмәләр;

10) поручитель раслаган бухгалтерлык балансы һәм хисап финанс елы өчен һәм соңгы хисап датасына керемнәр һәм зыян турында хисап, аларны кабул итү турында салым органы тамгасы белән һәм төп акчалар, тәмамланмаган төзелеш, матди кыйммәтләргә табышлы акча салулар, озак сроклы финанс салулар, кыска сроклы финанс салулар, дебитор бурычлары, озак сроклы йөкләмәләр, кыска сроклы кредитлар һәм займнар, кредит бурычлары (һәр төр бурыч буенча) турында баланс статьяларының расшифровкаларын теркәп, аларга аңлатма язулары;

11) поручительнең соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

12) әлеге нигезләмәнең 14 пунктының 1 пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән елдан алдагы ел өчен гарантның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында гарант раслаган аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә ел саен аудитор тикшерүе узарга тиеш юридик затлар өчен);

13) поручительнең җитәкче имзалаган һәм поручительнең мөһере белән расланган чиста активлары хисабы.

Поручитель әлеге пунктның 3, 4, 8 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, финанс идарәсе аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

15. Поручительнең финанс идарәсенә кергән документлары кергән көнне теркәлә.

16. Поручитель тарафыннан тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 14 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, финанс идарәсе, документлар теркәлгән датадан башлап биш эш көненнән дә соңга калмыйча, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны гарантка кире кайтара.

17. Поручитель тарафыннан тапшырылган документлар әлеге нигезләмәнең 14 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килгән очракта, финанс идарәсе банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләүне үткәрә.

Финанс идарәсе тапшырылган документларны, документлар теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә поручительнең әлеге нигезләмәнең 13 пунктында каралган таләпләргә туры килүе предметына карый һәм поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә әлеге нигезләмә кушымтасында каралганча аның финанс хәленә анализ ясый.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча финанс идарәсе поручительнең финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү сәләте турында бәяләмә әзерли, бу хакта поручительгә бәяләмәне әзерләү датасыннан башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын бәяләү тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

Поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы

1. Поручительнең финанс хәлен бәяләү өчен база финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:

1) ликвидлык коэффициенты;

2) үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты;

3) рентабельлек күрсәткече.

2. Финанс нәтиҗәләрен исәпләү түбәндәге башлангыч мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) 1 нче форма (бухгалтерлык балансы);

2) 2 нче форма (финанс нәтиҗәләре турында хисап).

3. Ликвидлык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

1) абсолют ликвидлык коэффициенты;

2) тиз ликвидлык коэффициенты;

3) агымдагы ликвидлык коэффициенты.

4. Абсолют ликвидлык коэффициенты К1 түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К1 = \frac{\text{ден. средства } (1250) + \text{кр. фин. вложения} (1240)}{\text{тек. обязательства } (1500 - 1530 - 1540)},$$

монда:

акча - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (балансның 1250 нче юлы);

кыска сроклы финанс салулар – поручительнең хисап чоры ахырына формалашкан кыска сроклы финанс салулар (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Әйләнеш (түләү) срогы хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаганнар керә, әгәр ул 12 айдан артык булса (балансның 1240 нчы юлы);

агымдагы йөкләмәләр - поручительнең түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V баланс бүлеге нәтиҗәсенең (1500 нче юл), алдагы чор керемнәренең (1530 нчы юл) һәм бәяләү йөкләмәләренең (1540 нчы юл) аермасы буларак билгеләнә.

5. Тиз ликвидлык коэффициенты К2 акчаны хуҗалык әйләнешеннән оператив рәвештә азат итү һәм булган финанс йөкләмәләрен түләү сәләтен күрсәтә. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К2 = \frac{\text{деб. задолженность} (1230) + \text{кр. фин. вложения} (1240) + \text{ден. средства} (1250)}{\text{тек. обязательства } (1500 - 1530 - 1540)},$$

монда:

дебитор бурычы - түләнүе ел дәвамында көтелә торган дебитор бурычы (балансның 1230 нчы юлы);

кыска сроклы финанс салулар – поручительнең хисап чоры ахырына формалашкан кыска сроклы финанс салулар (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Әйләнеш (түләү) срогы хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаганнар керә, әгәр ул 12 айдан артык булса (балансның 1240 нчы юлы);

акча - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (балансның 1250 нче юлы);

агымдагы йөкләмәләр - поручительнең түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V баланс бүлеге нәтиҗәсенең (1500 нче юл), алдагы чор керемнәренең (1530 нчы юл) һәм бәяләү йөкләмәләренең (1540 нчы юл) аермасы буларак билгеләнә.

6. Агымдагы ликвидлык коэффициенты К3 түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\text{К3} = \frac{\text{оборотные активы }(1200)}{\text{кр. обязательства }(1500 - 1530)},$$

монда:

әйләнештәге активлар - әйләнештәге активлар (1200 нче юл);

кыска сроклы йөкләмәләр - поручительнең түләү срогы хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк булган кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Зурлык V баланс бүлеге нәтиҗәсенең (1500 нче юл) һәм алдагы чор керемнәренең (1530 нчы юл) аермасы буларак билгеләнә.

7. Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты

Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты К4 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$\text{К4} = \frac{\text{собственный капитал }(1300)}{\text{заемный капитал }(1500 + 1400 - 1530)},$$

монда:

үз капиталы – үз капиталы һәм резервлары (балансның 1300 нче юлы);

заем капиталы – финанс йөкләмәләре. Зурлык, алдагы чор керемнәрен (балансның 1530 нчы юлы) исәпкә алмыйча, кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр (балансның 1500 нче һәм 1400 нче юллары) суммасы буларак билгеләнә.

8. Рентабельлек күрсәткече К5 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$\text{К}_5 = \frac{\text{прибыль от продаж (2200)}}{\text{выручка (2110)}},$$

монда:

сатудан табыш - продукция сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2200 нче юлы);

керем - керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2110 нчы юлы).

9. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чик зурлыклар билгеләнә.

10. Алынган зурлык һәм чик зурлыклар нигезендә, һәр зурлык өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең чик зурлыклары һәм күрсәткечләрнең факттагы зурлыкларына бәйле рәвештә категорияне сайлау кагыйдәләре 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица. Күрсәткечләрнең чик зурлыклары һәм күрсәткечләрнең факттагы зурлыкларына бәйле рәвештә категорияне сайлау кагыйдәләре

| Коэффициентлар | 1 категория (күрсәткечнең яхшы зурлыгы) | 2 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек зурлыгы) | 3 категория (күрсәткечнең канәгатьләнмәслек зурлыгы) |
|---|---|---|---|
| $К_1$ | 0,2 дән артык | 0,1 - 0,2 | 0,1 дән ким |
| $К_2$ | 0,8 дән артык | 0,5 - 0,8 | 0,5 тән ким |
| $К_3$ | 2,0 дән артык | 1,0 - 2,0 | 1,0 дән ким |
| $к_4$ | | | |
| сәүдә предприятиеләре | 0,6 дән артык | 0,4 - 0,6 | 0,4 тән ким |
| башка тармак предприятиеләре | 1,0 дән артык | 0,7 - 1,0 | 0,7 дән ким |
| $к_5$ | 0,15 тән артык | 0,0 - 0,15 | 0,0 дән ким (рентабельле булмаган) |

11. Җыелма бәя зурлыгы (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Вес_1 \text{ x } Категория_1 + Вес_2 \text{ x } Категория_2 + Вес_3 \text{ x } Категория_3 + Вес_4 \text{ x } Категория_4 + Вес_5 \text{ x } Категория_5,$$

монда:
Авырлыкi – җыелма бәядә Кi күрсәткеченең авырлыгы, i = 1, 2, 3, 4 яки 5.
Күрсәткеч авырлыгының зурлыклары 2 нче таблицада күрсәтелгән
Категорияi - Кi күрсәткеченең зурлыгы карый торган категория.
Категорияi = 1, 2 яки 3.

2 нче таблица. Җыелма бәяне исәпләгәндә файдаланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең авырлыгы |
|---|---|
| Абсолют ликвидлык коэффициенты К1 | 0,11 |
| Тиз ликвидлык коэффициенты К2 | 0,05 |
| Агымдагы ликвидлык коэффициенты К3 | 0,42 |
| Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты К4 | 0,21 |
| Рентабельлек күрсәткече К5 | 0,21 |

12. Җыелма бәя зурлыгы нигезендә поручительнең финанс хәле:
1) әгәр җыелма бәянең зурлыгы 1,05 тән артмаса, яхшы була;

2) әгәр җыелма бәянең зурлыгы 1,05 тән артык булса, ләкин 2,4 дән артмаса, канәгатьләнерлек була;

3) әгәр җыелма бәянең зурлыгы 2,4 тән артса, канәгатьләнмәслек була.

Поручительнең чиста активларының күләме бирелә торган бюджет кредитының өчкә тапкырланган суммасы күләменнән ким булырга тиеш түгел.